ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«4. Агымдагы финанс елына муниципаль берәмлекләр бюджетларына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме һәм агымдагы финанс елына i-муниципаль берәмлеге бюджетына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенция күләме әлеге Методиканың 3 пунктындагы алтынчы – уналтынчы, унтугызынчы – егерме өченче, егерме алтынчы һәм егерме җиденче абзацларында билгеләнгән күрсәткечләрнең агымдагы финанс елының 1 ноябренә факттагы саннарыннан чыгып үзгәртелергә мөмкин.

Әлеге пункт нигезләмәләрен исәпкә алып, агымдагы финанс елына муниципаль берәмлекләр бюджетларына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү һәм агымдагы финанс елына і-муниципаль берәмлеге бюджетына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенция күләмен исәпләп чыгару әлеге Методиканың 2 һәм 3 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнехانов

Казан, Кремль
2024 ел, 25 декабрь
№ 105-ТРЗ